| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

21.02.2025 — № 126-п

«2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрне стерильләштерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 08 ноябрендәге 1129-п номерлы «2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрне стерильләштерү» муниципаль программасын раслау турында» карары белән расланган «2022-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрне стерильләштерү» муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспорты таблицасында «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | Программаны Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның гомуми күләме 181,676 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2022 ел-100,000 мең сум;<br>2023 ел-14,585 мең сум;<br>2024 ел-67,091 мең сум;<br>2025 ел-0,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы Карарына ярашлы рәвештә төгәлләштереләчәк. |

»;

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итү» 5 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**5. Программаны ресурслар белән тәэмин итү**

Программаны Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның гомуми күләме 181,676 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2022 ел-100,000 мең сум;
2023 ел-14,585 мең сум;
2024 ел-67,091 мең сум;
2025 ел-0,000 мең сум.

Программаны финанслау күләме фаразлау характерында һәм Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы Карарына ярашлы рәвештә төгәлләштереләчәк.».

1.3. Программаның 1 нче кушымтасын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ruрәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче М. Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта

«2022-2025 елларга Татарстан
Республикасы Саба муниципаль районы
территориясендә хуҗалары булган
этләрне стерильләштерү» муниципаль
программасына 1 нче кушымта

## **Программаны гамәлгә ашыру чаралары**

| № т/б | Исеме | Финанслау чыганагы | Финанслау күләме еллар буенча, мең сум. | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
| 1. | Саба муниципаль районы территориясендә хуҗалары булган этләрне стерильләштерү чараларын үткәрү | Саба муниципаль районы бюджеты | 100,000 | 14,585 | 67,091 | 0,000 |
| | **Барлыгы:** | | **181,676** | | | |